КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 июль г.Казань № 773

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче; 2018 ел, 31 май, 411 нче; 2019 ел, 15 гыйнвар, 4 нче; 2020 ел, 3 март, 162 нче; 2020 ел, 21 апрель, 310 нчы; 2020 ел, 27 июль, 627 нче; 2021 ел, 1 октябрь, 942 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1358 нче; 2022 ел, 22 февраль, 154 нче; 2022 ел, 18 август, 854 нче; 2023 ел, 6 апрель, 419 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) (01.06.14*).»;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

өченче абзацта «билгеләнгән» сүзе алдына «81 статьясындагы 18.2 пунктында» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «каралган» сүзе алдына «, Россия Федерациясе Урман кодексының 81 статьясындагы 18.1 пунктында» сүзләрен өстәргә;

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман саклауны гамәлгә ашыра;»;

3.3.1.1 пунктчаның өченче абзацында «3 өлеше» сүзләрен «4 өлеше» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының хезмәт таныклыгы турында» 2007 ел, 13 август, 385 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 ноябрь, 962 нче; 2022 ел, 11 июль, 670 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының хезмәт таныклыгы формасы һәм аны тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «2007 ел, 12 февраль, 38 нче» сүзләре алдына «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) таныклыкның эчке сул һәм уң яклары:

| | |
|---|---|
| Министерство лесного хозяйства<br>Республики Татарстан<br><br>УДОСТОВЕРЕНИЕ N ______<br>______________________<br>(фамилия)<br>______________________<br>(имя)<br>______________________<br>(отчество (при наличии))<br>Дата выдачи «__» ________ 20__ г.<br><br>Министр – Главный<br>государственный лесной инспектор<br>Республики Татарстан ________ ______________<br>подпись (фамилия, инициалы) | ______________________<br>______________________<br>(должность)<br>______________________<br>______________________<br>(должность государственного инспектора)<br><br>При исполнении полномочий имеет право осуществлять федеральный государственный лесной контроль (надзор), лесную охрану в лесах, расположенных на землях лесного фонда, в пределах своей компетенции.»; |

2.2 пунктның унҗиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Times New Roman шрифтының 10 нчы размерлы юл хәрефләре белән эшләнгән «При исполнении полномочий имеет право осуществлять федеральный государствен-ный лесной контроль (надзор), лесную охрану в лесах, расположенных на землях лесного фонда, в пределах своей компетенции.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының таныклыгы, түбәндәгеләргә таянып, урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман саклауны гамәлгә ашыручы зат вазыйфасына билгеләү турындагы боерык нигезендә бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлекләре;

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренең – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы урманчылыкларның Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба –

Министрлык) боерыгы белән раслана торган федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затлары исемлеге.»;

3.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 974 нче; 2016 ел, 14 гыйнвар, 12 нче; 2016 ел, 2 ноябрь, 807 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1094 нче; 2017 ел, 27 июнь, 441 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 апрель, 296 нчы; 2018 ел, 26 ноябрь, 1053 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2019 ел, 28 август, 732 нче; 2019 ел, 7 сентябрь, 892 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1248 нче; 2020 ел, 15 май, 391 нче; 2020 ел, 18 август, 704 нче; 2020 ел, 25 сентябрь, 873 нче; 2020 ел, 25 декабрь, 1190 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 26 нчы; 2021 ел, 1 февраль, 45 нче; 2021 ел, 21 июль, 627 нче; 2021 ел, 13 август, 719 нчы; 2021 ел, 15 ноябрь, 1075 нче; 2021 ел, 27 декабрь, 1294 нче; 2022 ел, 23 март, 260 нчы; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 16 май, 449 нчы; 2022 ел, 3 август, 755 нче; 2022 ел, 18 ноябрь, 1233 нче; 2023 ел, 27 гыйнвар, 57 нче; 2023 ел, 11 февраль, 140 нчы; 2023 ел, 25 март, 351 нче; 2023 ел, 18 апрель, 489 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13.2 пунктның «020000Р.16.1.Л102АА01200» юлындагы 4 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру»;

13.4 пунктның «020000Р.16.1.Л102АА01200» юлындагы 4 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2019 ел, 27 декабрь, 1222 нче; 2020 ел, 10 июнь, 480 нче; 2020 ел, 31 август,

762 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1143 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1017 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 15 июль, 677 нче; 2022 ел, 4 август, 757 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1202 нче; 2023 ел, 3 март, 201 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына), 20.123 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман саклауны, федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлекләрен раслау турында» 2022 елның 21 гыйнварындагы 36 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 ноябрь, 1210 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлекләрен раслау турында»;

1 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карар (әлеге карарның 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктындагы җиденче һәм сигезенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин